**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 3 сентябрь № 613

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Финанс министрлыгы мәсьәләләре» 2005 ел, 6 июль, 323 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Финанс министрлыгы мәсьәләләре» 2005 ел, 6 июль, 323 нче карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2008 ел, 29 май, 340 нчы; 2009 ел, 2 февраль, 56 нчы; 2010 ел, 17 декабрь, 1078 нче; 2010 ел, 30 декабрь, 1156 нчы; 2011 ел, 4 ноябрь, 918 нче; 2013 ел, 30 сентябрь, 696 нчы; 2013 ел, 16 декабрь, 995 нче; 2014 ел, 17 гыйнвар, 21 нче; 2014 ел, 31 гыйнвар, 52 нче; 2015 ел, 26 февраль, 116 нчы, 2016 ел, 19 май, 323 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) белән расланган Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.1. Министрлык түбәндәге функцияләрне башкарган өчен җавап тота:

бюджет процессы белән идарә итү (Татарстан Республикасы һәм дәүләт бюджеттан тыш фондлары бюджеты) (01.02.1 <*>);

Татарстан Республикасы дәүләт бурычы белән идарә итү (01.02.2 <*>);

бюджетара мөнәсәбәтләрне җайга салу (01.02.3 <*>);

дәүләт кыйммәтле кәгазьләре эмиссиясе һәм эш итүе белән идарә итү (01.02.4 <*>);

финанс-бюджет өлкәсенә контроль (01.02.5 <*>);

Татарстан Республикасының эшләмәүче халкын мәҗбүри медицина иминиятләвен оештыру (04.02.12 <*>).»;

5.3 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«Министрлык, аның структур бүлекчәләре эшчәнлеген оештыру мәсьәләләре буенча боерыклар рәвешендә норматив хокукый актлар чыгара;

министр урынбасарлары, структур бүлекчәләр җитәкчеләре һәм хезмәткәрләре эшчәнлеге нәтиҗәлелегенең төп күрсәткечләре исемлеген боерыгы белән раслый;

дәүләт идарәсенең беркетелгән функцияләрен тормышка ашыру процессларының Министрлык тарафыннан үтәлү стандартларын боерыгы белән раслый;

эшчәнлек нәтиҗәлелегенең ирешелгән күрсәткечләренә бәйле стимуллаштыру түләүләре зурлыгын исәпләү тәртибен билгеләү турында нигезләмәне боерыгы белән раслый.»;

түбәндәге эчтәлекле 5.3.1 пунктчасын өстәргә:

«5.3.1. Министрлыкның структур бүлекчәләре һәм хезмәткәрләре эшчәнлеге нәтиҗәлелеген бәяләү министр боерыгы белән расланган эшчәнлек нәтиҗәлелегенең төп күрчәткечләре исемлеге нигезендә башкарыла.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков